Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге составына керүче
Околоток-Яңасала авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

23 ноябрь 2022 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге составына керүче Околоток-Яңасала авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Околоток-Яңасала авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- Околоток-Яңгасала торак пунктында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Околоток-Яңгасала т. п. да су белән тәэмин итү системасы эчтәлеге (тирән насослар сатып алу);
- Околоток-Яңгасала т. п. да урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (килешү буенча);
- Околоток-Яңгасала т. п. да урамнарның машиналар йөрү өлешен кышкы тәртиптә тоту (урамнарны чистарту);
- Х.Такташ урамына 5 данә чүп контейнерлары сатып алу;
- М. Җәлил урамын ремонтлау өчен вак таш сатып алу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гилазиева А.Р.

Биектау авыл җирлеге башлыгы: Гилазиева А.Р.